| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.09.2022 п.г.т.Алексеевское № 387

**Татарстан Республикасы Алексеевский муниципаль районы территориясендә урып-җыю кампаниясе чорында авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре(механизаторлар) арасындагы конкурс турында**

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башлыгы тарафыннан 07.07.2021 елдан Россия Федерациясе Хезмәт Кодексы һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы белән расланган бөртекле һәм кузаклы культуралар җыюда мәшгуль эшчеләрне премияләү шартлары нигезендә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүне һәм авыл хуҗалыгы хезмәткәрләрен бүләкләүне оештыруны стимуллаштыру максатларында.

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә урып-җыю кампаниясе чорында авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре (механизаторлар) арасында конкурс үткәрү турында Нигезләмәне (кушымта) расларга.

2.Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы Г.К. Мусинга конкурс үткәрүне һәм аңа йомгак ясауны контрольгә алырга тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының финанс-бюджет палатасына әлеге карарны тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5.«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә урып-җыю кампаниясе чорында авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре (механизаторлар) арасында конкурс турында» Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 01.09.2021 ел, № 316 карары үз көчен югалткан дип танырга.

6.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.А. Гайнуллин**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
19.09.2022 елның
387 нче карарына кушымта

**Урып-җыю кампаниясе чорында авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре (механизаторлар) арасында конкурс үткәрү турында**
**Нигезләмә**

1.Конкурс Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә урып-җыю кампаниясе барышында югары күрсәткечләргә ирешкән иң актив механизаторларны мотивацияләү максатларында үткәрелә.

Конкурс урып-җыю кампаниясе вакытында агымдагы елның 7 июленнән 30 сентябренә кадәр, түбәндәге номинацияләрдә һәр 7 көн саен үткәрелә:

- «Беренче төркем комбайнында эшләүче иң яхшы механизатор»;
- «Икенче төркем комбайнында эшләүче иң яхшы механизатор»;
- «Өченче төркем комбайнында эшләүче иң яхшы механизатор»;
- «Дүртенче төркем комбайнында эшләүче иң яхшы механизатор»;
- «Бөртекле һәм кузаклы культураларны чаптыруда үзйөрешле чапкычның иң яхшы механизаторы»;
- «Ындыр табагына комбайннан ашлык ташу буенча иң яхшы машина йөртүче».

2. Катнашучыларга түбәндәге таләпләр куела:

2.1 «Беренче төркем комбайнында эшләүче иң яхшы механизатор» номинациясенә:

- авыл хуҗалыгы предприятиесе яки КФХ хезмәткәре;
- СК-5 Нива, Енисей комбайнында эшләр үткәрү.

2.2. «Икенче төркем комбайнында эшләүче иң яхшы механизатор» номинациясенә:

- авыл хуҗалыгы предприятиесе яки КФХ хезмәткәре;
- Дон-1500 комбайнында эшләр үткәрү.

2.3. «Өченче төркем комбайнында эшләүче иң яхшы механизатор» номинациясенә:

- авыл хуҗалыгы предприятиесе яки КФХ хезмәткәре;
- Полесье, Акрос, Нью-Холланд, Кейс, Мега-204, Мега-208 комбайнында эшләр үткәрү.

2.4. «Дүртенче төркем комбайнында эшләүче иң яхшы механизатор» номинациясенә:

- авыл хуҗалыгы предприятиесе яки КФХ хезмәткәре;
- Тукано, Мега-370, Лексион, Торум комбайнында эшләр үткәрү.

2.5. «Бөртекле һәм кузаклы культураларны чаптыруда үзйөрешле чапкычның иң яхшы механизаторы» номинациясенә:

- авыл хуҗалыгы предприятиесе яки КФХ хезмәткәре;
- Макдон и КСУ-1,0 чапкыч белән эш башкару.

2.6. «Ындыр табагына комбайннан ашлык ташу буенча иң яхшы машина йөртүче» номинациясенә:

- авыл хуҗалыгы предприятиесе яки КФХ хезмәткәре;

2.7. Субсидия алучыларга килешү төзергә планлаштырылган айга кадәрге айның беренче көненә туры килергә тиеш таләпләр:

субсидия алучыларның салымнар, җыемнар, иминият взнослары, пенялар, штрафлар, процентлар, салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаска тиеш;

субсидия алучыларның Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджетына кире кайтару буенча кичектерелгән бурычы, аннан башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләр һәм Алексеевск муниципаль районы бюджеты алдында бүтән кичектерелгән бурычлары булмаска тиеш.

3.Конкурста җиңүчеләрне билгеләү өчен түбәндәге составта конкурс комиссиясен төзергә:

Комиссия рәисе:

Гайнуллин О.А. - Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе

Комиссия әгъзалары:

Мусин Г.К. - Алексеевск муниципаль районы авыл
хуҗалыгы һәм азык-төлек
Идарәсе башлыгы (килештерү буенча)

Михайлов Ю.В. -авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
Идарәсенең җитештерү-маркетинг
бүлеге консультанты (килештерү буенча)

Поповнин В.В. -авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
Идарәсенең җитештерү-маркетинг
бүлеге консультанты (килештерү буенча)

Шкильменская М.В. - Алексеевск авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
Идарәсенең финанс-икътисад бүлеге
консультанты (килештерү буенча)

5.Бәйгенең һәр чорында катнашу өчен заявкалар атна саен Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында Авыл хуҗалыгы һәм азык төлек министрлыгының Авыл хуҗалыгы һәм азык төлек идарәсенә хисап чорының соңгы эш көнендә электрон рәвештә тапшырыла: alekseevsk.alsu@tatar.ru.

Җыелган гаризалар көн ахырында конкурс комиссиясе рәисенә җибәрелә.

6.Комиссия утырышлары атна саен комиссия рәисе карары буенча үткәрелә. Комиссия утырышы күпчелек әгъзалар катнашкан очракта хокуклы санала. Җиңүче катнашучыларның күпчелек тавышлары белән ачык тавыш бирү юлы белән билгеләнә.

7. Комиссия конкурста җиңүчеләрне һәм призерларны комбайн төркеменә һәм ашлык суктыру күләменә карап билгели һәм алар арасында премияләр бүлеп бирә:

1 урын – 2000 (ике мең) сум;

2 урын – 1000 (мең) сум.

Комиссия конкурста җиңүчеләрне һәм призерларны билгели һәм алар арасында чабылган бөртекле һәм кузаклы культуралар мәйданына карап премияләр бүлеп бирә (Макдон и КСУ-1,0 кулланып):

1 урын – 2000 (ике мең) сум;

Комиссия конкурста җиңүчеләрне һәм призерларны билгели һәм ташылган ашлык күләменә карап алар арасында премияләр бүлеп бирә:

1 урын – 2000 (ике мең) сум;

2 урын – 1000 (мең) сум.

**Башкарма комитетының**
**Эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**